| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ<br>«ГОРОД ЧИСТОПОЛЬ»<br>ЧИСТОПОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ<br>ГОРОДСКОЙ СОВЕТ** | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ<br>**ЧИСТАЙ<br>ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ** |

***Решение*** ***Карар***

**2024 елның 26 сентябре** **Чистай шәһәре** **№34/3**

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль
районы Чистай шәһәр Советының
2020 елның 29 декабрендәге 5/2 номерлы
карары белән расланган Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы «Чистай шәһәре»
муниципаль берәмлегенең җирле бюджеты
акчалары исәбеннән инвестиция проектлары
буенча муниципаль гарантияләр бирү тәртибендәге
1.3 пунктының гамәлдә булуын туктатып тору турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексының 96_6 һәм 220_1 статьяларына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору һәм 2024 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары үтәлеше үзенчәлекләрен билгеләү турында» 2023 елның 2 ноябрендәге 520-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советының 2020 елның 29 декабрендәге 5/2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы "Чистай шәһәре" муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары вәкаләтләре нигезендә муниципаль гарантияләр бирү өлешендә инвестиция проектлары буенча җирле бюджет акчалары исәбеннән муниципаль гарантияләр бирү тәртибенең 1 статьясындагы 1.3 пунктының гамәлдә булуы, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советының чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына) шәһәр бюджеты турында карары, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Башкарма комитеты карарлары, шулай ук муниципаль

гарантия бирү турындагы шартнамә нигезендә, 2025 елның 1 гыйнварына кадәр туктатыла.

2. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирле бюджеты акчалары исәбеннән инвестиция проектлары буенча муниципаль гарантияләр бирү тәртибен раслау турында» 2020 елның 29 декабрендәге 5/2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 30 маендагы 30/3 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында һәм (яисә) «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (www.chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләсе буенча даими депутат комиссиясенә О.В. Добронравовага йөкләргә.

Чистай муниципаль районы
Чистай шәһәре Башлыгы — Д. А. Иванов